| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАП-ТОМБАРЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2025 ел. Потап-Томбарлы авылы № 8

Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 23.12.2024 № 4 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2025 № 304-ФЗ Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районының Потап-Томбарлы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 23.12.2024 № 4 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлегендә:

2.5.1 пунктының 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк,» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ белешмәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

2.16.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) бердәм портал кулланып, машина укыла торган форматта электрон

документ алырга, орган тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче Башкарма комитет
Потап-Томбарлы авыл җирлеге С.А. Козлова